| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.03.2019 г.Казань № 154

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 22 мартында 5489 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия формасында грант бирү өчен кулланыла торган документларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 466 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия формасында грант бирү турында килешү формасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү

тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының көчен югалтуын тану турында» 2016 елның 29 декабрендәге 1046 номерлы карарын тормышка ашыру максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия формасында грант бирү өчен кулланыла торган документларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 466 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия формасында грант бирү турында килешү формасының 3.5 пунктына, аны киләсе редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.5. Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчегә 15 декабрьдән соң күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен грант күчерү социаль хезмәтләр күрсәтелгән елдан соңгы елның 1 мартына кадәр социаль хезмәтләр күрсәтелгән елда гамәлдә булган тарифлар буенча агымдагы финанс елында каралган акча чикләрендә башкарыла».

Министр Э.Ә. Зарипова